ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

11.05.2021 с.Старое Дрожжаное № 189

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеген камилләштерү белән бәйле Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 27 декабрендәге 365-ФЗ номерлы һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 16 июнендәге 319 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлекнең 2.2 пунктында:

в пунктчасын түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

«в) административ процедуралар составына, эзлеклелегенә һәм аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук күп функцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре. Бүлектә гомуми үзенчәлекләр белән берләшкән кайбер мөрәҗәгать итүчеләрнең бу хезмәтләрне күрсәтү тәртибен, шул исәптән алар тарафыннан мөрәҗәгать ителгән дәүләт яки муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата булган дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтү вариантлары булырга тиеш.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Административ регламент структурасы мәгълүмат технологияләре өлкәсендә норматив-хокукый җайга салуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән таләпләр нигезендә мондый хезмәт күрсәтү процедураларын автоматлаштыруны тәэмин

итә торган тиешле хезмәт күрсәтү процедураларын машинкада укыла торган тасвирлауны күздә тотарга тиеш.»;

2) 3 бүлегендә:

3.1 пунктны түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Административ регламент проектын эшләүне муниципаль хезмәт күрсәтүче орган башкара.

Җирле үзидарә органнарының административ регламентлары проектларын эшләү һәм килештерү дәүләт мәгълүмат системасында һәм (яисә) муниципаль мәгълүмат системасында гамәлгә ашырыла, алар Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре реестрын, муниципаль хезмәтләр реестрын электрон рәвештә алып баруны тәэмин итә.

Җирле үзидарә органы Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль хезмәтләр реестры" муниципаль мәгълүмат системасы турында 2010 елның 28 сентябрендәге 649 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәт һәм аның нигезендә эшләнә торган административ регламент турындагы белешмәләрне "Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль хезмәтләр реестры" муниципаль мәгълүмат системасын алып баруга вәкаләтле икътисад бүлегенә, тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү йөкләнгән ОМСУны билгеләүче (үзгәртүче) хокукый актлар үз көченә кергән көннән башлап, эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн өчендә җибәрелә.

Административ регламентлар проектлары дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы яисә җирле үзидарәнең вәкаләтле органы үткәрә торган бәйсез экспертиза һәм экспертиза узарга тиеш.

Әлеге пунктның беренче абзацы нигезендә эшләнелә торган административ регламентлар проектларына хокукый һәм коррупциягә каршы экспертиза үткәрү үзенчәлекләре муниципаль норматив хокукый акт белән раслана.

Җирле үзидарә органнары әлеге пунктның беренче абзацында каралган экспертиза уздыру максатларында үз региональ мәгълүмат системаларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре реестрларын һәм муниципаль хезмәтләр реестрларын алып бару максатларында төзелгән муниципаль мәгълүмат системаларын файдаланырга хокуклы.

Вәкаләтле җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелә торган административ регламентлар проектларына экспертиза ясау предметы булып административ регламентлар проектларының аларга 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон һәм аның нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актларга туры килүен бәяләү тора.»;

3.2 пунктның икенче абзацында «, шулай ук административ регламентлар проектларында бәйсез экспертиза нәтиҗәләрен исәпкә алу» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында»

2011 елның 09 мартындагы 111 номерлы (2012 елның 28 мартындагы 50 номерлы, 2015 елның 19 маендагы 203 номерлы, 2018 елнын 16 октябрендәге 572 номерлы редакциясендә) карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов